**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2698**
**27.05.2019**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр инфраструктурасын төзекләндерү дирекциясе» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында» 2019 елның 16 гыйнварындагы 126 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24, 5.25 пунктлары, шәһәр Уставының 53 маддәсенең 3 бүлеге нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр инфраструктурасын төзекләндерү дирекциясе» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында» 2019 елның 16 гыйнварындагы 126 нчы карарына, 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Җир эшләре башкаруда мәгълүмат-консультация бирү хезмәте күрсәтүгә тарифны, өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча, 2280,30 (ике мең ике йөз сиксән) сум 30 тиен күләмендә расларга.».

2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев